**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

# К А Р А Р

21.11.2016 № 104

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында 20 ноябрь 2016 елда узган мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2017 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭСы һәлакәтен бетерүдә катнашучылардан, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

– Иске Кырлай авылында ( Һади Такташ урамы, 1нче йорттан 7нче йортка кадәр – 150 м);

– Иске Иябаш авылында (Муса Җәлил урамы, 46нчы йорттан 47нче йортка кадәр – 18 м);

–Өтнә авылында (Салих Сәйдәшев урамы, 15нче йорттан 16нчы йортка кадәр – 48 м);

–Югары Әзәк авылында (Мәктәп урамы 8нче йорттан 10нчы йортка кадәр – 60 м);

–Түбән Мәтәскә авылында (Тукай урамы, 14нче, 14а йорттан –20 м, Түбән урам 1,2нче йорттан – 40 м, Киров урамы, 7нче йорттан 15нче йортка кадәр – 60 м, Мәктәп урамы, 4,11,15 йорттан – 60 м, Тынычлык урамы, 6нчы йорттан 11нче йортка кадәр – 50 м, Татарстан урамыннан чыкканда – 20 м);

– Югары Мәтәскә авылында (Дуслык урамы, 1нче йорттан 4нче йортка кадәр – 20 м, Тукай урамы, 2,4,6нчы йортлардан – 40 м, 9,11,15 йортлардан – 60 м, Яшьләр урамы, 1нче йорттан – 20 м);

–Мөндеш авылында (Чишмә урамы, 33нче йорттан 39нчы йортка кадәр – 80 м, 5нче йорттан 9нчы йортка кадәр – 80 м, Татарстан урамы, 25 нче йортта 28нче йортка кадәр – 60 м);

– Казиле авылында (Жиңү урамы, 11нче йорттан 14нче йортка кадәр – 70 м) урамга вак таш җәю;

– Иске Иябаш авылы зиратына койма кору (120 м) һәм тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл жирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1640 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-1448, бу 88,29% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 1337референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 92,33% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 111 кеше тавыш бирде, бу 7,67% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныpгa.

2. "2017 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Чернобыль АЭСы һәлакәтен бетерүдә катнашучылардан, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

– Иске Кырлай авылында ( Һади Такташ урамы, 1нче йорттан 7нче йортка кадәр – 150 м);

– Иске Иябаш авылында (Муса Җәлил урамы, 46нчы йорттан 47нче йортка кадәр – 18 м);

–Өтнә авылында (Салих Сәйдәшев урамы, 15нче йорттан 16нчы йортка кадәр – 48 м);

–Югары Өзәк авылында (Мәктәп урамы 8нче йорттан 10нчы йортка кадәр – 60 м);

–Түбән Мәтәскә авылында (Тукай урамы, 14нче, 14а йорттан –20 м, Түбән урам 1,2нче йорттан – 40 м, Киров урамы, 7нче йорттан 15нче йортка кадәр – 60 м, Мәктәп урамы, 4,11,15 йорттан – 60 м, Тынычлык урамы, 6нчы йорттан 11нче йортка кадәр – 50 м, Татарстан урамыннан чыкканда – 20 м);

– Югары Мәтәскә авылында (Дуслык урамы, 1нче йорттан 4нче йортка кадәр – 20 м, Тукай урамы, 2,4,6нчы йортлардан – 40 м, 9,11,15 йортлардан – 60 м, Яшьләр урамы, 1нче йорттан – 20 м);

–Мөндеш авылында (Чишмә урамы, 33нче йорттан 39нчы йортка кадәр – 80 м, 5нче йорттан 9нчы йортка кадәр – 80 м, Татарстан урамы, 25 нче йортта 28нче йортка кадәр – 60 м);

– Казиле авылында (Җиңү урамы, 11нче йорттан 14нче йортка кадәр – 70 м) урамга вак таш җәю;

– Иске Иябаш авылы зиратына койма кору (120 м) һәм тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева